

Кадошкино районы Большие Поляны авыл жирлегенә кергән Насакан-Потьма халкы һәм житәкчеләре Н.Х. Долотказина, балаларга уеннар очен мәйданчык ясаган очен, Рустам Абдрахман улы Агишевка рәхмәт белдерәләр, дип яза Татьяна Румянцева «Возрождение» газетасында.

Исса елгасы буенда урнашкан Насакан-Потьма - Кадошкино районындагы кечкенә авыл һәм анын халкы турында, берничә ел элек зурлап Сабантуй vткәрvләре турында бик матур мәкаләләр язган идек. Анда даими рәвештә 23 кеше яши. Коры һава торышында бирегә машинада грунт юлы буйлап йориләр, ә пычракларда - Исса елгасынын икенче ярындагы авылга жәяvләп асылмалы кvпер аша кvчәргә момкин. Бvген, аз кеше яшәvенә карамастан, бер генә урамнан торган авыл бик тә жыештырылган; йортлар каршында бернинди чvп-чар юк, һәркайда vлән чабылган. Хәтта даими яшәми торган йортларнын да барысы да жыештырылган. Бу авылнын ин яшь кешесе - Регина Советова. Фотода ул ике яшь тулмаган сабые белән. Яшьләр кvбрәк шәһәргә китәргә омтыла. Әмма бу кечкенә генә авыл шулай да балалар тавышы белән тулган: жәйге каникуллар вакытында Мәскәv, Саранскидан унга якын бала жыела. Яллар вакытында да авыл картларына балалары, оныклары килә. Киләчәк буын тәрбияле vссен, кирәкмәгән эшләр белән шогыльләнмәсеннәр очен, аларга кызыклы почмак - балалар уеннары очен мәйданчык булдыруны авыл халкы кvптән теләгән иде. Әмма кем эшләр һәм нинди акчага дигән сорау берникадәр вакыт кон тәртибендә торган булган. Бу мәсьәләдә Рустам Абдрахман улы Агишев инициатива кvрсәтә. Ул - дачник, авылга сезон саен килә. Сvз унаеннан шуны да әйтеп китәргә кирәк; ул халыкка кvп мәсьәләләрне хәл итvдә ярдәм итә, булыша. Нәтижәдә, жәй коне Насакан-Потьмада ял итvче балаларга ата-аналары, әби-бабайлары, мәйданчык булдыру очен, яраклы территорияне сайлап алалар. Карусельләр кую очен территорияне бергәләп чистарталар. Кыска гына вакыт эчендә мәйданчык жиһазландырыла да. Хәзер балалар карусельләрдә рәхәтләнеп вакытларын vткәрәләр. Олкәннәрнен, балаларнын ни- чек уйнавын кvзәтv очен, унайлы урындыклар да урнаштырылган. Уеннар очен мәйданчык бик унайлы һәм матур ял урыны булып чыккан. Мәйданчык турында авыл халкы болай ди.

